РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района
423303, Азнакаевский район, с. Агерзе, ул.Г.Ахметовой, д.9а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге башкарма
комитеты
423303, Азнакай районы, Әгерҗе авылы, Г.Ахметова урамы, 9а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 май 2021 ел № 12

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 15.02. 1 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карары белән расланган, административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында (15.11.2019 №15, 27.02.2020 № 5, 24.04.2020 № 10, 17.11.2020 № 17, 08.02.2021 № 4, 14.05.2021 № 11 карарлар редакциясендә)**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 15.02 1 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» 15.11.2019 №15, 27.02.2020 № 5, 24.04.2020 № 10, 17.11.2020 № 17, 08.02.2021 № 4, 14.05.2021 № 11 карарлар редакциясендә) карары белән расланган, административ регламентларга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Торак урыны, муниципаль торак фонды, гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

а) 2.5 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык һәм аларның нотариаль таныкланган тәрҗемәсе, гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясенең консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;»;

б) 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

1.2. Социаль наем шартнамәсе буенча күрсәтелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

а) 2.5 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык һәм аларның нотариаль таныкланган

тәрҗемәсе, гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясенең консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык;»;

б) 1 нче кушымтаны әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http//aznakayevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык                                        Н.Н.Хәсәнов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГЕРЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1061688004747
ИНН 1643008121/КПП 164301001

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
18.05.2021 № 12

________________________________________
(муниципаль берәмлекнең
________________________________________
җирле үзидарә органы исеме)
________________________________________
____________________________ (алга таба – мөрәҗәгать итүче).
(физик затларөчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлү, телефон)

Муниципаль милектәге торак урынын гражданга социаль наем шартнамәсе буенча бирү турында гариза

Социаль наем шартнамәсе буенча торак бина бирүегезне сорыйм.

Торак урын адресы: муниципаль район (шәһәр округы), торак пункт ______________________ ур.__________________ йорт __________ .

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) Мөрәҗәгать итүче граждан паспортының һәм аның гаилә әгъзаларының яисә шәхесне таныклый торган башка документларның күчермәләре;

2) Чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе, гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясенең консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;

3) Граждан-мөрәҗәгать итүче һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документларның күчермәләре (шартнамә, ордер, торак урын бирү турында карар һәм башка документлар);

4) Граждан-мөрәҗәгать итүче йә аның гаилә әгъзасын торак урыны бирү хокукына ия гражданнар категориясенә торак законнары нигезендә чираттан тыш кертергә нигез бирә торган документлар:

- дәвалау медицина учреждениесеннән медицина белешмәсе - хроник авыруның авыр формасы белән авыручы, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган исемлек буенча аның белән бергә яшәү мөмкин булмаган авыру гражданның гаиләсе составында булганда;

- опекун билгеләү турында опека һәм попечительлек органнарыннан белешмә – хокукка сәләтсез граждан исеменнән гамәлдә булган опекун тарафыннан исәпкә алу турында гариза имзаланган очракта;

- ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларның мәгариф һәм башка учреждениеләрдә, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә, тәрбиягә алган гаиләләрдә, гаилә тибындагы балалар йортларында булу-булмавын, опеканы (попечительлекне) туктатканда, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт тәмамланганнан соң яисә ирегеннән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаны үтәүче учреждениеләрдән кайтканнан соң аларның статусын раслый торган документлар.

5) граждан-мөрәҗәгать итүче һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документларның күчермәләре (шартнамә, ордер, торак урын бирү турында карар һәм башка документлар);

6) 31-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 12, 18, 19 статьяларындакүрсәтелгән башка документлар (гражданнарны аз керемлеләр дип тану өчен).

Сораган вакытта сканерланган документларның төп нөсхәләрен бирергә вәгъдә итәм.

| ____________ | ____________ | ______________________ |
| --- | --- | --- |
| (дата) | (имза) | (ФИО) |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымта
18.05.2021 № 12

_______________________________________________
(муниципаль берәмлекнең

_______________________________________________
җирле үзидарә органы исеме)

_______________________________________________
_____________________________ (алга таба - мөрәҗәгать итүче).
(физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлү, телефон)

Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарны алмаштыру документларын рәсмиләштерү турында
гариза

Торак урынын алыштыру документларын рәсмиләштерүегезне сорыйм.

Торак урын адресы: муниципаль район (шәһәр округы), торак пункт ______________________ур.__________________ йорт __________ .

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) шәхесне таныклый торган документлар;

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эшләсә);

3) Граждан-мөрәҗәгать итүче һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документларның күчермәләре (шартнамә, ордер, торак урын бирү турында карар һәм башка документлар);

4) Чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе, гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясенең консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар

5) БТИ техник паспортларыннан этажлар буйлап план (булган очракта) һәм экспликация белән язу.

Сораган вакытта сканерланган документларның төп нөсхәләрен бирергә вәгъдә итәм.

_______________ _____________ ______________________________
(дата) (имза) (ФИО)